
**Сүзле уен «Кар бөртекләре»**

Кар, кар, кар ява,
Бураннарны туздыра.
Кулларга төшеп эри,
Үзе бик тиз туңдыра.
Йомшак карны алабыз,
Аннан туплар ясыйбыз.
Кар атышып уйныйбыз,
Бик күңелле яшибез.
Суыктан без курыкмыйбыз,
Рәхәтләнеп уйныйбыз.
Кар бөртекләрен куып,
Уйнаудан һич туймыйбыз.

***Бергәләп өйрәник***



# ***Кыш***

***Әти-әниләр өчен к ярдәмлек***

***(5-6 яшь)***

**Сынамышлар. «Халык әйтсә, хак әйтә»**

(әти-әниләр белән берлектә өйрәнгән сынамышларны әйтү):

а) Кояш бик еракта булып күренсә, салкын булыр.

б) Багана сызгырса, суык булыр.

в) Каз аягын күтәреп торса, салкын булыр.

г) Чыпчык агачның очына кунса – көн салкын була, түбән ботакларына кунса – җил чыга.

**Табышмак**

Ак кына, вак кына,
Ак мамык сымак кына.
Югала, юк була,
Учта тотсаң чак кына. (Кар бөртеге)

Әби килгән сагынып,
Ак чикмәнен ябынып. (Кыш килү)

**Әңгәмә. «Кыш килде»:**

- Ни өчен тирә-як ап-ак?
- Елның кайсы вакыты?
- Кыш айлары нинди айлар?
- Кышын нинди үзгәрешләр була?
- Кыш сезгә ошыймы? Ни өчен?
- Кыш көне нинди уеннар уйнарга яратасыз?

**Тел шомарткыч. [ш], [с] авазлары**

а) Ыш-ыш-ыш,
Безгә килде салкын кыш.
б) Су-су-су,
Суыкта битләр алсу.

**Шигырь уку: Г.Зәйнашева. «Кыш килде»**

Ап-ак тун киеп кыш килде,
Яфрак-яфрак кар ява.
Без дә кидек җылы туннар,
Куркытмый салкын һава.
Чормадан сикереп төште
Чаңгылар һәм чаналар.
Ак мамыктай ап-ак кышны
Сагынып көткәннәр алар.
Сөенәбез, шатланабыз,
Күңелле үтә кышлар.
Чаңгы, чана, тимераяк –
Безнең иң якын дуслар.

**Иҗади күзаллау уены «Карның файдасы һәм зыяны»**

- Карның нинди файдасын беләсез?
- Карның нинди зыяны бар?

***

**Сүзле-хәрәкәтле уен «Кар ява»**

(балалар, сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар).

Ябалак-ябалак кар ява,
Чыгабыз уйнарга,
Урамга – һавага.
Чуарлап өсләрне,
Ябалак кар, яу-яу!
Без ясыйбыз кардан тау,
Ак мамыктай тузгып яу!
Бик дәү булсын безнең тау!